БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ
ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №38 (7055) | 29 март, 1990 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.




## Квартал планын— вакытыннан элек

Хуҗалыкара төзелеш берләшмәсенең Октябрь районы 1 нче ПМКсы эшчеләре агымдагы елның беренче квартал планын 104,2 процентка үтәделәр. Бу уңышка ирешүдә бигрәк тә Р. Г. Мусин бригадасы ташчыларының өлеше байтак. Алар «Большевик» колхозында клуб салдылар. Шулай ук Р.Х. Гәрәев җитәкләгән балта осталары бригадасы да зур тырышлык күрсәттеләр. Алар хезмәтен «Кондырча» махсус хуҗалыгында яшәүчеләр бәяли алалар, чөнки бу осталар нәкъ шунда бозаулар абзарын яңартып кору белән мәшгульләр. Ә Р. Хәсәншин җитәкчелегендәге монтажчылар «Төрнәс» совхозында йортлар төзүдә фидакарь хезмәт күрсәтәләр. Бу бригадаларның уртача еллык эшләп чыгару дәрәҗәсе 140 процентка җитте. Коллектив киләчәктә дә югары күрсәткечләр белән барырга тырыша.

**Ф. МӨЛЕКОВ.**

Ибраһим Хисмәтуллович Фәйзуллинның техника иярләвенә берничә дистә ел гомер узган инде. Төрле маркадагы тракторлар белән күптөрле эшләр башкарды ул, һәрберсендә тырышлык һәм намус белән эшләде. Хәзер ул МТЗ-80 тракторында хуҗалыктан сөт ташый. Язгы чәчү чорына исә гадәттәгечә РМГ-6 агрегатын тагып, орлык ташуда булачак. Бер елны да ул игенчеләр хезмәтендә тоткарлыкка юл куйганы юк, быел да шуны максат итә.

Рәсемдә: XXI партсъезд исемендәге колхоз механизаторы И. Х. Фәйзуллин.



## *Көлегез, көлегез, файдасы зур, белегез!*

1 апрель—юмор көне. Элек-электән килгән традиция буенча ул көнне халык шаяра, күңел ача, рәхәтләнеп ял итә. Мәзәк хәлләр, маҗаралар күрәсегез, рәхәтләнеп көләсегез килсә, ул көнне иртәнге сәгать 9 да нефтьчеләр микрорайонының «Огонек» кибете, шикәрчеләр поселогының сәүдә үзәге янындагы, ә 10 сәгатьтә шәһәр үзәгенә килегез. Соңга кала күрмәгез, югыйсә кызыклы уеннарда катнашудан, мәзәкләрне караудан мәхрүм калырсыз.

Бу көнне райпо һәм шәһәрнең эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре төрле товарлар чыгарырга вәгъдә итәләр. Җәмәгать туклануы предприятиеләре хәзерләгән күп төрле ашамлыкларны авыз итми калмагыз тагын. Чемпионнар күтәрә алмаган авырлыкларны күтәрә алуда көч сынашырга теләсәгез, спорт ярышларында катнаша аласыз. Концерт карасагыз эчегезне уып-уып көлерсез. Костюмнар парады узачак, рәссамнар үзегезгә дусларча шаржлар әзерләп бирәчәк.

Бәяләре төшерелгән товарларны сату буенча аукцион үткәрелә.

Иң кызыгы—лотерея уйнату булыр, мөгаен. Төрле әйберләрне отмый калмагыз. Лотерея билетлары райпоның барлык кибетләрендә дә сатыла.

Көлергә, күңел ачарга килүче һәркем, юмор көненә рәхим итегез!

## Алар партиягә ышаналар

Март аенда яшь коммунистларга партия билетлары тапшыру тантанасы булды. КПСС райкомының кече залында башлангыч партия оешмалары секретарьлары, партия ветераннары җыелган. Менә язмада В. И. Ленин тавышы яңгырый. Яшьләрнең генә түгел, мондый тантаналарда күп тапкырлар катнашкан өлкәннәрнең дә дулкынланудан йөрәкләре кысыла.

Менә яшь коммунистларга КПСС райкомының беренче секретаре Х. Х. Морадыймов мөрәҗәгать итә. Яшьләрне КПСС сафларына керүләре белән котлап, ул бу карарның киләчәк тормыш юлларын, эшләрен билгеләүче буласына ышаныч белдерә:

—Килер бер көн, сезнең һәрберегез ил өчен, партия һәм халык өчен гади булмаган көннәрдә КПСС сафларына керүен зур горурлык белән искә алыр.

Шуннан соң партия билетлары тапшыру башланды. Яшь коммунистлар арасында Гәйтән мәктәбе директоры А. М. Авдеева, сөт-май заводы лаборанты В. Г. Захарова, Синдряков исемендәге колхозның көтүне яңарту буенча технологы Ә. Ф. Абдрахманова, Мичурин исемендәге колхозда председательнең терлек азыгы җитештерү буенча урынбасары В. В. Маланьин, район элемтә узелы операторы Ф. Х. Волкова, 73 нче ВПЧ работниклары М. М. Шәрәфиев һәм Д. М. Мөхәммәдиев бар.

Бу көнне «Москва» колхозы механизаторы А. В. Паймурзин, сөт-май заводы көйләүчесе В. К. Васильев, Кузнецов исемендәге колхоз председателе В. А. Трифонов, ремтехпредприятиенең баш инженеры А. П. Петряков кандидатлык карточкалары алдылар.

Яшьләргә беренчеләрдән булып партия, сугыш һәм хезмәт ветераны, ремтехпредприятиенең элекке слесаре, I дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары һәм күп медальләр кавалеры П. М. Арефьев мөрәҗәгать итте. Катлаулы көрәш һәм хезмәт юлы үткән Петр Матвеевичның бүген дистәләгән шәкерте, бай тәҗрибәсе һәм яшьләргә әйтер сүзе бар, әлбәттә.

Аннан соң сүз алган район элемтә узелы партия оешмасы секретаре Л. И. Ильина һәм ВЛКСМ райкомының беренче секретаре И. И. Куликов шулай ук яшь коммунистларны котладылар һәм бу исемгә лаек булуларын теләделәр.

Җавап сүзе белән М.М. Шәрәфиев чыкты.

—Без партиягә, аның халык язмышындагы авангард роленә ышанабыз. Партиягә кереп, без шәхси уңайлыклар эзләмибез. Безнең максатыбыз бер: мөмкин кадәр яхшырак эшләргә, бөтен гомеребезне халыкка хезмәт итүгә багышларга.

Һәм, гадәттәгечә, истәлеккә —фото. Бу—традиция. Чөнки мондый көн гомердә бер генә була бит.

**Г. МӨБӘРӘКШИНА.**

— Делегатлар сүзе —

## Съезддан соң сөйләшү

Мәгълүм булганча, 23 мартта Казанда хатын-кызларның III республика съезды булды. Газета хәбәрчесе безнең район делегатларының икесенә съезддан алган тәэсирләре белән бүлешүне сорап мөрәҗәгать итте.

**А. С. Мотаһирова, Колбай Мораса авылы. хатын-кызлар советы председателе.**

Мин хатын-кызлар съездында икенче тапкыр. Үткән съезд бик тантаналы булып истә калган. Бу съезддан шул күренде: хатын-кызлар хәрәкәтендә иҗтимагый һәм сәяси активлык үскән, аларның кайгырту мәйданы киңәйгән, һәр нәрсәне демократик ачыклык шартларына куеп хәл итәргә тырышу өстәлгән. Съездда хатын-кызларга ана буларак бала тәрбияләүдә шартлар тудыру, аларга профессиональ яктан үсү мөмкинлекләре булдыру, аның җәмгыятьтәге ролен күтәрү турында җитди сөйләшү булды.

Хатын-кызлар советын үз сүзен әйтергә, иң дәрәҗәле органга да үз лидерларын күрсәтергә һәм үз җанын борчыган күп мәсьәләләрне реаль хәл итәргә сәләтле җәмәгать оешмасы итеп күрергә теләү —һәркемнең тел төбендә шул фикер ятты. Андый максатка ирешү өчен көрәшне җирле хатын-кызлар советыннан башларга кирәк, әлбәттә. Мин дә, башкалар кебек үк, советның көчен, дәрәҗәсен, вәкаләтен күтәрерлек эшләр торгызу нияте белән канатланып кайттым съезддан.

**Л. Н. Дилмөхәммәтова, район социаль-тәэминат бүлеге мөдире:**

Съезд ачыклык шартларында үтүе белән ошады миңа. Элекке еллардагы җыелышлар кебек, кәгазьдән укыган коры чыгышлардан тормады ул, ә хатын-кызларның йөрәгеннән чыккан эчкерсез сөйләшү булды. Иң элек, хатын-кызларда шәфкатьнең яңа чагылышы — гаилә тибындагы балалар йортлары оештыру, тәрбиягә балалар алу кебек адымнар хуплап каршы алынды. Әмма андый гаиләләргә игътибар, ихтирам җитенкерәмәү турындагы сүз дә кискен барды.

Мин җитәкче урыннарга хатын-кызларны кую турында сөйләшүне дә бик вакытлы кузгатылды дип уйлыйм. Эшлекле сыйфатлары буенча хатын-кыз ирләрдән калыша дигән фикер белән кайсыбыз килешә ала? Шулай булгач, аларны тигез өслеккә куеп фикер йөртергә вакыт. Ә хатын-кыз аналар турында сөйли башласак... Хәер, бусына ерак китәсем килми. Арабыздан бер делегат —7 бала анасы Миния Касыймовна Кудряшовага юл буе сокланып бардык. Сабырлык, гаҗәеп пөхтәлек, шәфкать нуры балкып торган ачык йөзле бу ханым балалары турында шундый итеп сөйли— аларның һәрберсенә гашыйк булырсың. Ә үзендә никадәр зирәклек, практик киңәшләр, рецептлар. Съездда күп балалы аналарга игътибар турында сүз барганда, мин һәрчак аны күз алдында тоттым. Мондый аналар алдында ил белән баш иярга тиешбез дип уйлыйм.

## Шәфкатьле булыйк

23 мартта В. И. Ленин исемендәге Балалар фондының район советы утырышы булды. Совет председателе Ю. П. Шартынова җыелган иптәшләрне ятим, гарип һәм авыру балаларга хезмәт күрсәтү буенча билгеләнгән программаның үтәлеше барышы белән таныштырды.

Биредә мәктәп ашханәләрен продуктлар белән тәэмин итүне канәгатьләнмәслек итеп оештыру, балаларның сыйфатсыз туклануы турында җитди кисәтүләр ясалды.

Утырышта шәфкать фондына средстволар җыюны оештыру мәсьәләсе кискен куелды. Бу эш әлегә массакүләм төс алмады әле. Бүгенге көнгә бары берничә шәфкать акты гына үткәрелде. Район ата-аналар конференциясендә 105 сум акча җыелды, ВЛКСМ райкомы үткәргән «Кылларның моңлы авазы» концерты 170 сум керем бирде. Иң зур өлеш —970 сум акча —3 нче шәһәр мәктәбе ата-аналары катнашында гы чарадан керде. Барлык бу взнослар билгеләмәсе буенча —ятим балаларга, аз керемле һәм күп балалы гаиләләргә, инвалид балаларга тотыла.

Балалар фонды советы мәктәпләр каршындагы ата-аналар комитетларын, җәмәгать оешмаларын, йорт комитетларын, культура-агарту һәм спорт учреждениеләрен, ветераннар клубларын әлеге шәфкать актында катнашуның төрле формаларын һәм чараларын эзләргә чакырды. Совет председателе предприятие һәм оешма җитәкчеләренә язмыш тарафыннан кимсетелгән балалар турында киң кайгырту күрергә, фонд советы чараларына сизгер карарга өндәп мөрәҗәгать итте. Шул рәвешле җыелган акчалар Балалар фондының район советына тупланачак.

**Г. ДАВЫДОВА,**

Балалар фондының район советы члены.

